**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№424**
**25.01.2021**

«Ел рәссамы-2020»
шәһәр конкурс күргәзмәсен
үткәрү турында

Башкарма комитетның 2019 елның 31 октябрендәге 5598 номерлы карары белән расланган 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә мәдәниятне үстерү муниципаль программасын үтәү йөзеннән, шәһәрдә сынлы сәнгатьне үстерүдәге яңа тенденцияләрне ачыклау һәм профессиональ рәссамнарга ярдәм күрсәтү максатыннан

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның мәдәният идарәсенә «Ел рәссамы-2020» шәһәр конкурс күргәзмәсен «Яр Чаллы картиналар галереясы» муниципаль бюджет учреждениесендә 2021елның февралендә үткәрергә.

2. Расларга:

1) «Ел рәссамы-2020» шәһәр конкурс күргәзмәсен үткәрү турында нигезләмәне, 1 нче кушымтада каралганча;

2) «Ел рәссамы-2020» шәһәр конкурс күргәзмәсенең оештыру комитеты һәм эшләрне сайлап алу һәм җиңүчеләрне билгеләү буенча күргәзмә комитеты составларын, 2 нче кушымтада каралганча.

3. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «Ел рәссамы-2020» шәһәр конкурс күргәзмәсен оештыру һәм үткәрү чыгымнарын финанслауга акча бүлеп бирүне 2021 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетының «Мәдәният» 08.01 бүлегендә (бүлекчәсендә) каралган акчалар хисабына 140 000 (бер йөз кырык мең) сум күләмендә, 3 нче кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе                                                                                    Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 25 гыйнварындагы
424 номерлы карарына
1 нче кушымта

«Ел рәссамы-2020»
шәһәр конкурс күргәзмәсен үткәрү турында
нигезләмә

1. «Ел рәссамы-2020» шәһәр конкурс күргәзмәсе (алга таба – конкурс) сынлы сәнгать өлкәсендә Яр Чаллы шәһәрендә рәсем сәнгатенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү, шулай ук Чаллы рәссамнарының иҗади активлыгын стимуллаштыру һәм аларның иҗатын популярлаштыру максатларында үткәрелә.

2. Конкурсның бурычы – сәнгатьнең төрле жанрларында югары һөнәри осталык дәрәҗәсе белән аерылып торган, автор стиле үзенчәлегенә, яңалыкка һәм оригинальлеккә ия әсәрләрне ачыклау.

3. Әсәрләр түбәндәге номинацияләрдә карала:

1) рәсем сәнгате;
2) графика;
3) скульптура;
4) яңа исемнәр (яшь рәссамнарны күрсәтү).
5) декоратив-гамәли сәнгать;
6) халык сәнгате;
7) Яр Чаллы. Тарих һәм хәзерге заман.

Конкурста катнашучыларга тәкъдим ителә торган эшләр тематикасына Яр Чаллы шәһәре төзелеше тарихын һәм шәһәрнең яңа образын кертергә тәкъдим ителә.

4. Конкурсны үткәрү өчен оештыру комитеты (алга таба – оештыру комитеты) һәм эшләрне сайлап алу һәм җиңүчеләрне билгеләү буенча күргәзмә комитеты (алга таба – күргәзмә комитеты) төзелә, аның составы Башкарма комитет карары белән раслана.

5. Күргәзмә комитет рәисе күргәзмә комитеты әгъзалары арасыннан ачык тавыш бирү юлы белән турыдан-туры күргәзмә эшләрен сайлап алу көнендә сайлана.

6. Конкурска эшләрне сайлап алу күргәзмә комитеты тарафыннан 2021 елның 13 февраленә кадәр гамәлгә ашырыла.

7. Күргәзмә комитеты әлеге нигезләмәдә күрсәтелгән номинацияләр буенча конкурс җиңүчеләрен ачык тавыш бирү юлы белән, гади күпчелек тавыш нигезендә билгели. Бәхәсле очракларда һәм тавышлар тигез булганда күргәзмә комитеты рәисе ике тавышка ия.

Күргәзмә комитеты әгъзасы конкурс күргәзмәсендә катнашкан очракта аның әсәрен номинациядә карап тикшерү һәм сайлап алу аның тавышыннан башка гамәлгә ашырыла.

Күргәзмә комитеты карары утырышның беркетмәсе белән рәсмиләштерелә. Конкурсның абсолют җиңүчесе номинантлар арасыннан сайлана, игълан ителә һәм Мәдәният хезмәткәрләре көненә багышланган тантаналы чарада бүләкләнә.

8. Конкурста сынлы сәнгатьнең теләсә кайсы төрендә эшләүче Яр Чаллы шәһәренең профессиональ рәссамнары һәм рәссамнары катнаша ала. Башка шәһәрләрдән катнашучыларның әсәрләре күргәзмәгә куела ала, ләкин конкурс сайлап алуында катнашмый. Һәр катнашучыдан 2020 елда башкарылган, төрле дәрәҗәдәге күргәзмәләргә куелган 3 тән артык булмаган эш кабул ителергә мөмкин. Эшләр «Яр Чаллы картиналар галереясы» муниципаль бюджет учреждениесендә түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Яр Чаллы шәһәре, 52/16 (3/01) йорт, тел. 38-16-24.

Катнашучы «Персональ мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 4 пункт нигезендә (конкурс үткәрү өчен

мәгълүмат әзерләү һәм файдалану максаты белән) персональ мәгълүматларын эшкәртүгә ризалыгын рәсмиләштерә.

Рәссам агымдагы елда вафат булган очракта, аның әсәрләрен күргәзмәгә кую өчен туганнары тәкъдим итә ала, ләкин ул эшләр күргәзмә комитеты тарафыннан номинацияләрдә каралмый.

9. Эшләр түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) югары һөнәри осталык;

2) индивидуальлек;

3) тема һәм сюжетны үзенчәлекле хәл итү;

4) новаторларча якын килү;

5) үзенчәлекле иҗади фикерләү;

6) автор стиленең үзенчәлеге;

7) төрле дәрәҗәдәге (шәһәр, региональ, зональ, республика, Россия һәм халыкара) күргәзмәләрдә катнашу.

10. Һәр әсәр каталог мәгълүматлары белән бергә бирелергә тиеш.

11. Җиңүчеләр дипломнар белән бүләкләнә.

12. Иң яхшы сәнгать әсәрләре фондларны тулыландыру максатыннан «Яр Чаллы картиналар галереясы» МБУның фонд-сатып алу эксперт комиссиясе тарафыннан сатып алу өчен сайлап алына, даими саклау актлары һәм шартнамәләр белән рәсмиләштерелә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева